ЖОМГА
5
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 29 (6751)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ТЫЛНЫҢ ФРОНТКА ЯРДӘМЕН ТОРГАН САЕН АРТТЫРЫЙК!

Сталинград! Кадерле һәм героик Сталинград безнеке! Анда яңадан Кызыл Байрак горур җилферди. Герой шәһәр үзенең революцион традицияләрен нык саклады һәм тагын бер тарихи җиңүгә иреште. Кара ният белән, совет кешеләрен кол итү, безнең байлыкларыбызны талау өчен килгән хәшәрәт дошманны сытып бетерде һәм юк итте. Сталинград районында дошман үзенең каберен тапты. «2 нче февральдә, Дон фронты гаскәрләре немец фашистларының Сталинград районында чолганып алынган гаскәрләрен бетерүне тулысынча төгәлләделәр. Безнең гаскәрләр Сталинградтан төньяктарак чолганып алынган дошманның каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм аны коралын ташларга мәҗбүр иттеләр. Сталинград районында дошманның каршылык күрсәтә торган соңгы үзәге сытып ташланды. 1943 нче елның 2 нче февралендә Сталинград янында булган тарихи сугыш безнең гаскәрләрнең тулы җиңүе белән тәмам булды». Совет Информбюросының һәрбер белдерүе көчле җиңү авазы булып яңгырый.

«Сталинград янында чолганып алынган дошман гаскәрләрен бетерүне уңышлы төгәлләвегез белән Сезне һәм Дон фронты гаскәрләрен котлыйм.

Бик яхшы сугыш хәрәкәтләре өчен Дон фронтының барлык сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына рәхмәт игълан итәм.

Верховный Баш Командующий
И. СТАЛИН».

Дон фронты гаскәрләренә юлбашчының инде бу икенче котлавы. Иптәш Сталинның фронтовикларны котлавы барлык совет сугышчыларын яңа җиңүләргә рухландыра. Кызыл Армия һөҗүм итә, җиңүле рәвештә алга бара. Дошман чигенә, Көнбатышка кысыла. Шулай да бу әле тулы җиңү дигән сүз түгел. Дошман әле тар-мар ителмәгән һәм бигрәк тә юк ителмәгән. Ә ул, һичшиксез, юк ителергә, тамыры корытылырга тиеш. Һәм бу көн килер, дошман, әлбәттә, юк ителер! Ләкин булган уңышлар белән тынычлану,—ул, большевикларга хас түгел. Билгеле, дошманның ярасы зур! Шуңа карамастан, ул әле кайбер кабахәтлекләр эшләве, төрле авантюраларга баруы мөмкин. Бу хәл бездән тагын да оешканрак булырга, хәлсезләнгән дошманны тәмам сытып бетерү өчен кирәк булганнарның барысын да эшләүне таләп итә.

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказы белән рухланган хезмәт ияләре үз постларында торып, яңа уңышларга ирешәләр, Кызыл Армиягә сугыш кораллары эшләүдә, азык продуктлары җитештерүдә үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Тыл фронтка барысын да җитештереп тора. Кызыл Армия дошманны кыйнап бетерсен өчен, уңышлы рәвештә һаман да алга, көнбатышка таба барсын өчен аңа ярдәмебезне тагын да арттырыйк, сугыш самолетларын, танкларны, орудиеләрне, сугыш припасларын күбрәк һәм күбрәк бирик, ашлыкны, итне, май, сөтне һәм башка продуктларны тагын да мулрак бирик! Бу, тылның изге бурычы.

Республикабызның колхозчы крестьяннары «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 100 миллион сум акча туплап, госбанкның урыннардагы бүлекләренә керттеләр. Юлбашчыбызның котлавы белән рухланган хәлдә, республикабызның колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр, мәктәп балалары самолетлар эскадрильясе төзелешенә средство туплауны башлап җибәрделәр. Бу хәрәкәт көннән-көн җәелә. Аңа киң юл бирелсен өчен, средство туплау эше киңәя барсын өчен барлык чаралар күрелсен. Шундый гүзәл хәрәкәт үз агымына куелмасын һәм җитәкчелек ителсен. Бу өлкәдә республикабызның күп районнары Октябрь районыннан үрнәк алырга һәм самолетлар эскадрильясе төзелешенә средство туплауны бу райондагыча алып барырга тиешләр.

Һөҗүм итүче сөекле Кызыл Армиягә һәртөрле ярдәмебезне көчәйтик! Немец оккупантларына үлем!

Соңгы сәгатьтә

I.
ВОРОНЕЖДАН КӨНБАТЫШТАРАК БЕЗНЕҢ ТРОФЕЙЛАР ҺӘМ ДОШМАННЫҢ ЮГАЛТУЛАРЫ

Совет Информбюросының 30 нчы январь белдерүеннән мәгълүм булуынча, безнең гаскәрләр 27—29 нчы январьда булган сугышлар нәтиҗәсендә Воронеждан көнбатыштарак дошманның зур бер группасын чолгап алганнар иде. Соңгы көннәрдә безнең частьлар дошманның бу группасын бүлгәләделәр һәм хәзер юк итәләр. Дошманның чолганып алынган частьларының безнең гаскәрләр боҗрасыннан чыгарга маташулары барысы да җимерелде.

30 нчы январьдан 4 нче февральгә кадәр булган сугышлар нәтиҗәсендә безнең гаскәрләр дошманның чолганып алынган группировкасы составыннан 5.000 нән артык солдат һәм офицерларны юк иттеләр һәм 13.000 кешене плен алдылар.

Димәк, ВОРОНЕЖДАН көнбатыштарак безнең гаскәрләрнең һөҗүме вакытында, 27 нче январьдан 4 нче февральгә кадәр 27.000 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды.

3 нче февральдә венгерларның 3 нче армейский корпус командиры генрал-майор ШТОММ, бу корпусның артиллерия начальнигы артиллерия генералы ДЕШИН һәм корпус штабының оператив бүлек начальнигы генеральный штаб майоры ЧАТО плен алынды.

27 нче январьдан 4 нче февральгә кадәр булган сугышлар вакытында фронтның бу участогында безнең гаскәрләр, тулы булмаган саннар буенча, түбәндәге трофейларны КУЛГА ТӨШЕРДЕЛӘР: танклар—143, төрле калибрлардагы орудиеләр—516, минометлар—149, пулеметлар—582, винтовкалар—12.000, снарядлар—310.000, патроннар—400.000, радиостанцияләр—64, автомашиналар—2.361, мотоцикллар—447, тимер юл эшелоннары—32, төрле складлар—122.

Шул ук вакыт эчендә дошманның үтерелгән солдатлары һәм офицерлары гына да 17.000 нән артты.

II.
БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР КУПЯНСК, ЩИГРЫ ҺӘМ ТИМ ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1) Украинада безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, КУПЯНСК шәһәрен алдылар.

2) КУРСКИДАН көнчыгыштарак безнең гаскәрләр ЩИГРЫ шәһәрен һәм тимер юл станциясен һәм ТИМ шәһәрен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ

МОСКВА, КРЕМЛЬ,

ИПТӘШ И. В. СТАЛИНГА

Ватан сугышы фронтларында героик Кызыл Армиябезнең данлыклы хәрби уңышлары белән һәм Ленинград блокадасының өзелүе белән рухланып, Ленинград эшчеләре, эшче хатын-кызлары, инженер-техник работниклары, хезмәткәрләре, врачлары, укытучылары, әдәбият һәм сәнгать работниклары, йорт хозяйкалары, пенсионерлар, пионерлар һәм мәктәп балалары үзләренең саклык акчаларыннан «Ленинградлы» исемле танклар колоннасы, «Ленинград» исемле авиация берләшмәсе һәм артиллерия төзелешенә 74.500.000 сум акча җыйдылар.

Акча җыю ленинградлыларның үз ватаннарына, большевиклар партиясенә һәм Сезгә, иптәш Сталин, чиксез бирелгәнлегенең һәм мәхәббәтенең көчле демонстрациясе булды. Ленинградның хезмәт ияләре, күп айлар буена үз шәһәрләрен саклап, Ватанның куәтле булышлыгына таянып, блокаданың барлык авырлыкларын нык торып кичерделәр. Ленинград турында Сезнең кайгыртучанлык күрсәтүегез белән рухланган хәлдә, ленинградлылар үзләре көткән көн киләчәккә—Ленинград янында фашист бандаларны җиңү көне киләчәккә нык ышандылар. Дошман блокадасы боҗрасын өзү безнең көчебезне арттыра, гитлерчы кабахәтләрне һәм юлбасарларны тәмам тар-мар итү өчен безне фронтка тагын да күбрәк ярдәм күрсәтүгә туплый.

Кадерле остазыбыз һәм дустыбыз, Ленинградлыларның кайнар сәламен, Сезнең озак еллар яшәвегезне һәм сәламәт булуыгызны теләвен кабул итегез.

ВКП(б) ның Ленинград шәһәр комитеты
секретаре А. ЖДАНОВ.

ЛЕНИНГРАД ШӘҺӘРЕ

ВКП(б) ның Ленинград Шәһәр Комитеты секретаре иптәш ЖДАНОВКА

Ленинград шәһәренең «Ленинградлы» исемле танклар колоннасы, «Ленинград» исемле авиация берләшмәсе һәм артиллерия төзелешенә 74.500.000 сум акча җыйган эшчеләренә, эшче хатын-кызларына, инженер-техник работникларына, хезмәткәрләренә, врачларына, укытучыларына, әдәбият һәм сәнгать работникларына, йорт хозяйкаларына, пенсионерларга, пионерларга һәм мәктәп балаларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Кызыл Армиягә—сугыш самолетлары!

Самолетлар эскадрильясе төзүгә

Орденлы Татарстанның колхозчылары һәм барлык хезмәт ияләре танклар колоннасы төзү фондына 100 миллион сум акча туплап тапшырып, үз ватаннарына карата патриотлыкның иң югары үрнәген күрсәткәннәр иде.

Чүпрәле районы колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары танклар колоннасы төзү фондына тапшырылган 2 миллион 553 мең сум акчага өстәмә итеп, самолетлар эскадрильясе төзү фондына тагын 2 миллион 532 мең сум акча туплап тапшырдылар.

Октябрь районы колхозчылары самолетлар эскадрильясе төзүгә 2 миллион сум, Алабуга районы колхозчылары 1 миллион 126 мең сум, Буа районы колхозчылары 2 миллион сум, Апас районы колхозчылары 1 миллион 500 мең сум акча җыеп, Дәүләт банкысына тапшырдылар. Кайбер колхозчылар бу фондка зур суммада акча кертеп, Ватанга бирелгәнлекнең чын үрнәген күрсәтәләр. Калинин районы, Калинин МТС ындагы тракторчылар отрядының бригадиры булып эшләүче Сәет Бәширов үзенең саклык акчаларыннан 100 мең сумны самолетлар эскадирльясе төзү фондына бирде.

Дәүләт банкысында һәм аның бүлекләрендә самолетлар эскарильясе төзү фондына һәркөнне 100 меңнәрчә сум акча керүендә дәвам итә.

АЙЛЫК ХЕЗМӘТ ХАКЫ КҮЛӘМЕНДӘ

Арчадагы тулы булмаган урта мәктәп укучылары (директоры иптәш Шәмиев) «Татарстан укытучысы» исемендәге самолетлар эскадрильясе төзү фондына үзләренең берәр айлык хезмәт хаклары күләмендә акча керттеләр.

Н. ХӘЙРУЛЛИН.

СТАЛИН РАЙОНЫНДА

Героик Кызыл Армиягә сугыш машиналарын тагын да күбрәк җитештерү өчен Казанда средстволар туплау дәвам итә.

Сталин районы хезмәт ияләре авиаэскадирльяләр төзү фондына 1 миллион 186 мең сум акча һәм 191 мең сумлык заем облигацияләре туплап тапшырдылар. «Ширпотреб» артеле членнары һәм Главлесосбыт конторасы работниклары айлык хезмәт хаклары күләмендә акча туплап керттеләр.

Сталин районы мәктәпләрендә укучы балалар 60 мең сум туплап тапшырдылар. Шул исәптән 12 нче мәктәптә укучылар 7.100 сум, 35 нче мәктәптә укучылар 7.000 сум бүләк иттеләр.

ЛАЕКЛЫ ҖАВАП

ЧАЛЛЫ, 3 февраль. (Телеграф буенча). Молотов исемендәге колхоз председателе иптәш Мәрдиев бөек юлбашчының котлау телеграммасына җавап итеп Кызыл Армия фондына 40 пот ашлык һәм самолетлар эскдарильясе төзү өчен 5.000 сум акча бүләк итте.

Ә. ӘХСӘНОВ.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: Кече лейтенант М. Г. Лентяевның орудиесе дошман позициясен утка тота. Бу расчет берничә көн эчендә генә дә дошманның 9 ДЗОТ ын, 3 миномет батареясын һәм 3 орудиесен юк итте.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

4 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

4 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп һәм аның контратакаларын кире кайтарып, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Кущевская районында Н-че часть немецларның бер батальонга якын мотопехотасын тар-мар итте һәм дошманның 10 танкысын юк итте. Икенче бер участокта немецларның бер группа автоматчиклары, танклар ярдәме белән, безнең подразделениеләрнең сугышчан сафлары аркылы үтәргә маташканнар иде. Безнең сугышчылар мылтык-пулемет уты белән 100 гә якын немец автоматчикларын кырдылар һәм танкка каршы ата торган мылтыктан атып дошманның 2 танкысын яндырдылар.

* * *

Красный Лиман районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, бик каты сугыш нәтиҗәсендә, дошман тарафыннан көчле рәвештә ныгытылган, халык яши торган 6 пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган көрәштә генә дә 300 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, дошманның 4 танкысы, 7 танкеткасы, 3 бронемашинасы сафтан чыгарылды һәм берничә орудие кулга төшерелде.

* * *

Воронеждан көнбатыштарак Н-че часть немецларны халык яши торган 2 зур пункттан бәреп чыгарды. Безнең сугышчылар 5 орудие, 12 пулемет, 2 миномет, бер радиостанция һәм бер артиллерия склады кулга төшерделәр. Бер участокта лейтенант Зольвич командалыгындагы безнең автоматчиклар дошманның 600 кешедән торган һәм Алексеевкага бара торган колоннасына аттылар. Гитлерчылар чигенделәр һәм икенче авылга таба бордылар. Алар бу авылга килеп җиткәндә безнең сугышчыларның икенче бер группасы немецларны пулемет уты белән каршылады. Гитлерчылар арасында паника башланды. Аз гына бәрелеш нәтиҗәсендә 300 дән артык дошман солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Кырымда хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды сугыш хәрәкәтләренең ике ае эчендә 200 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырып ташлаган. Совет патриотлары дошманның 4 йөк автомашинасын юк иткәннәр һәм немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Паровоз, солдатлар утырган 4 теплушка һәм төрле сугыш техникасы төялгән 19 платформа җимерелгән.

Украинада хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды январь ае урталарында дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Паровоз һәм сугыш припаслары төялгән 16 вагон җимерелгән. Шуның өстенә немецлардан торган сакчылары бөтенләй юк ителгән.

* * *

Түбәндә Ростов өлкәсе, Сальск шәһәрендә немец-фашист кабахәтләренең канлы җинаятьләре турындагы акт игълан ителә: «Гитлерчы бандитлар һәм үтерүчеләр Сальск урамнарын кан белән күмделәр, шәһәребезне таладылар. Кеше ашаучы фашистлар һәркөнне дистәләрчә гражданнарны аттылар. 1 нче номерлы кирпеч заводы янында атып үтерелгән кешеләрнең гәүдәләре белән тулган 30 чокыр табылды. Тулы булмаган саннарга караганда, немецлар шәһәрнең 3.000 нән артык гражданнарын үтергәнче газаплаганнар һәм үтергәннәр. Фашист палачлар врач Дубинскаяны, депо слесаре Ганинны, колхоз председателе Гласконы, итекче Филоненконы, балалар бакчасы бухгалтеры Рудневаны һәм аның 80 яшьлек анасын, гражданка Бойконы, аның ике кеченә баласын һәм башка күп кешеләрне атып үтерделәр. Болардан тыш, шәһәрдә немецлар тарафыннан ерткыч төстә газапланган пленный кызылармеецларның һәм командирларның үле гәүдәләре табылды. Чигенгән чакта фашист бандитлар поликлиниканы, ике больницаны, биш мәктәпне, вокзалны, электр станциясен, тимер юлчылар клубын һәм күп кенә торак йортларны яндырдылар. Шәһәрне бөтенләй җимерелүдән бары тик Кызыл Армиянең тизлек белән һөҗүм итеп килүе генә коткарып калды». Актка Сальск хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма комитеты председателе Д. Шестерко, врач Е. Лекаркина, укытучы Е. Узлова, колхозчы Рева, эшче Донцов, хезмәткәр Проскурин, йорт хозяйкасы Щеглова, колхозчы Сытник һәм башкалар кул куйды.

* * *

Гитлер Германиясенең СССР га хыянәтчел һөҗүме вакытында Совет территориясендә булган Чех-Словакия гражданнарыннан төзелгән бер хәрби часть 30 нчы январьда төзелү пунктыннан Совет—Германия фронтының бер участогына китте. Чех-словакларның хәрби частена полковник Свобода командалык итә.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ

ПРОИЗВОДСТВО МӘСЬӘЛӘЛӘРЕН КҮБРӘК ЯКТЫРТЫРГА

Һәрбер районның теге яки бу үзенчәлеге була һәм анда чыга торган газетада бу үзенчәлек тулысынча чагылырга тиеш.

«Коммунага» газетасы Чистайда чыга. Чистай—промышленностьлы район. Анда төрле предприятиеләр, артельләр байтак. Газетада районның бу үзенчәлеге ничек чагыла соң?

Газетаның һәрбер номерында диярлек предприятиеләрдә ярышның барышы турында кыска-кыска хәбәрләр табарга мөмкин. Иптәш Сталинның докладлары һәм приказлары белән, Кызыл Армиянең героик һөҗүме белән рухланган эшчеләр коллективлары, социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдереп, үз өсләренә яңа йөкләмәләр алалар һәм аларны үтәү өчен көрәшәләр. «Путь» артеле коллективы, иптәш Сталинның докладын өйрәнгәннән соң, нормаларны арттырып үтәү белән җавап бирә. Киез итек басу һәм аяк киеме тегү цехлары планнарны 150, 180 процентка үти башладылар. Үз нормаларын 150—200 процентка үтәүче Шмилова, Гобәйдуллина, Шарова кебек стахановчылар үсеп чыгалар. (23 нче ноябрь, № 90).

Октябрь революциясенең 25 еллыгы көнендә чыккан 85—86 нчы номерда Н-че заводның партбюро секретаре И. Шуб ярыш нәтиҗәләренә йомгак ясый, алдынгы цехларны (7 нче номерлы цех) икешәр норма бирүче стахановчыларны (Медведева, Карпова) күрсәтә. Октябрь алды ярышында заводның алдынгы урынга чыкканлыгы һәм ВКП(б) Шәһәр Комитетының күчмә Кызыл Байрагын яулап алуы турында сөйли. Ворошилов исемендәге артельнең бәйләү цехында эшләүче Прасковья Паницева һәм Данилова иптәшләр моңа кадәр нормаларын үтәмичә киләләр иде. Алар, иптәш Сталинның тарихи докладын өйрәнгәннән соң, үзләренең көнлек нормаларын 150—200 процент итеп үтәүгә керештеләр (26 нчы ноябрь, №91). Бу—бик әйбәт факт. Бу турыда газета киңрәк тукталган булса тагын да яхшырак булган булыр иде.

Ләкин шулай да, газета предприятиеләр тормышы белән җитәрлек шөгыльләнә, дигән нәтиҗәгә килеп булмый әле. Бу өлкәдә байтак мөһим темаларны газета бөтенләй читләтеп үтә. Мәсәлән, экономия өчен көрәш мәсьәләсен алып карыйк. Бу турыда без өч айга нибары бер баш мәкалә генә күрәбез (22 нче октябрь, №82). Анда мәсьәлә бик дөрес, кискен куелып, экономия өчен көрәшмәүче, файдалы отходларны әрәм-шәрәм итүче «Труд» күн заводы, механика заводы тәнкыйтьгә алына. Ләкин бу темага газетада шуннан башка һичбер материал юк. Шулай ук, уйлап табу һәм рационализация мәсьәләләрен дә газета бөтенләй яктыртмый. Яңа кадрлар белән эшләү, яшь эшчеләрне өйрәтү, аларның квалификацияләрен күтәрү мәсьәләсендәге уңышлар яки кимчелекләр турында да газетадан һичбер материал табып булмый. Бу мәсьәлә буенча, күптән түгел «Трикотаж» фабрикасына эшләргә кереп, хәзер инде дүрт машинага хезмәт күрсәтүгә ирешкән Гобәйдуллина чыгышы бик әйбәт (№ 85—86). Ләкин бу материал үзенең ялгызлыгы белән бөтенләй югалып кала. Мондый чыгышларны газетада бәйрәм уңае белән генә түгел, ә системалы рәвештә оештырырга кирәк. Яңа эшче кадрларны тәрбияләү өлкәсендә булган кимчелекләр дә нык тәнкыйть ителергә тиешләр.

Халык өчен киң куллану товарлары эшләп чыгару—бүгенге көннең гаять әһәмиятле политик бурычларыннан берсе булып тора. Ләкин газета моны бөтенләй оныткан диярлек. Бу турыда газета битләрендә бер нәрсә дә язылмый.

Хәзер, Кызыл Армиянең 25 еллыгы якынлашу уңае белән, Чистай шәһәре предприятиеләре һәм артельләре киң куллану товарлары эшләп чыгару буенча махсус рәвештә яңа йөкләмәләр алдылар һәм Казан шәһәрен ярышка чакырдылар. Бу ярышның барышын, алынган йөкләмәләрнең үтәлүен һәм арттырып үтәлүе өчен көрәшне системалы рәвештә яктыртып бару—газетаның төп бурычларыннан берсе булырга тиеш.

Гомумән, Чистай кебек, предприятиеләргә һәм артельләргә шактый бай булган шәһәрдә чыгучы газета производство тормышы белән хәзергегә караганда күбрәк шөгыльләнергә, аны тулырак яктыртырга, бу мәсьәлә буенча төрле тематикадагы материалларны номердан номерга урнаштыра барырга тиеш.

Партия мәгарифе йорты ачылды

Шушы елның 1 нче февралендә Казанда, Бауман урамында ВКП(б) Шәһәр Комитетының партия мәгарифы йорты ачылды. Бу йортның яхшы җиһазландырылган уку залы, үзлегеннән укучылар өчен аерым бүлмәсе, 80 мең дала китаплары булган зур көтепханәсе, хәрби кабинеты һәм лекцияләр өчен аерым залы бар.

Партия мәгарифе йортында лекторлар системалы рәвештә эш алып барачаклар. Февральдә иң яхшы лекторлар тарафыннан: «Төньяк Африкадагы сугыш хәрәкәтләренә обзор», «Ленин—Сталин партиясе—җиңүне оештыручы», «Сталин Кызыл Армиянең һәм совет халкының полководецы» һ. б. темаларда лекцияләр оештырыла. Бу лекцияләрне хәрби белгечләр Дьяконов, Комонов, Саралидзе иптәшләр укыячаклар.

Партия мәгариф йортында һәркөнне ВКП(б) тарихы, халыкара хәлләр, агымдагы момент һәм хәрби пропаганда буенча консультацияләр үткәрелә.

Шәһәрдәге партия работниклары, пропагандистлар өчен, Ленин—Сталин әсәрләре һәм партия-оештыру эше буенча даими семинарлар була. Якын көннәрдә «Бөек Ватан сугышы» дигән темада күргәзмә оештырыла.

ҖИРЛЕ ПРОМЫШЛЕННОСТЬ РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘГЕ КИҢӘШМӘСЕ

Шушы көннәрдә җирле промышленность предприятиеләре җитәкчеләренең, производство һәм хуҗалык активының республика күләмендәге киңәшмәсе булып үтте. Җирле промышленность предприятиеләренең 1942 нче елдагы эш йомгаклары һәм 1943 нче елгы бурычлары турындагы доклад белән Татарстан АССР Җирле промышленность халык комиссары иптәш Шкребель чыкты. Докладчы узган елдагы эшкә тулы анализ ясап, быелгы бурычларны билгеләп үтте.

1943 нче елда җирле промышленность узган елдагыга караганда продукцияне 23,5 миллион сумга артык эшләп чыгарырга тиеш. Шул исәптән өлкә промышленносте буенча 8,5 миллион сумлык һәм район промышленносте буенча 15 миллион сумлык продукция артык эшләп чыгару күздә тотыла. 13,1 миллион сумлык киң куллану товарлары, шул исәптән җирле чималдан һәм отходлардан 8,6 миллион сумлык продукция эшләп чыгару планлаштырыла.

1943 нче елда җирле чималдан һәм отходлардан киң рәвештә файдаланырга һәм шулар базасында яңадан-яңа производстволар оештырырга кирәк булачак. Җирле чимал һәм отходлар белән эшләүгә карамастан, җирле промышленность илгә һәм фронтка отлично сыйфатлы гына продукция эшләп чыгарырга тиеш.

Алда торган бурычларны уңышлы үтәп чыгу өчен җирле промышленность предприятиеләрендә социалистик ярышны киң җәелдерергә, хезмәт дисциплинасын ныгытырга, эшчеләрнең көнкүреш шартларына игътибарны көчәйтергә кирәк.

Доклад буенча фикер алышуларда Тымытык райпромкомбинаты бухгалтеры Васильева, Казан шәһәр промкомбинатының скорняк-тегү фабрикасы директоры Елизаров, Зеленодольск шәһәр промкомбинаты техноругы Соколов, райпромкомбинат директорларыннан Бронников (Яңа Чишмә), Ласточкин (Олы Тархан), Феактистов (Арча), Җиһанова (Кайбыч), Чистай галантерея фабрикасы директоры Барзинков, Казан шәһәр промкомбинасы директоры Мещанова һәм башкалар чыгып сөйләделәр. Алар үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, наркомат алдындагы таләпләрен белдерделәр. Киңәшмәдә ВКП(б) ның Казан шәһәр комитетыннан Игнатов һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре Дмитриев иптәшләрнең чыгышлары булды.

СЛАВЯННАР КОМИТЕТЫ ПЛЕНУМЫ

Москвада ике көн буена, 31 нче январьда һәм 1 нче февральдә, славяннар комитетының пленумы булды. Пленум комитет президенты генерал-лейтенант А. С. Гундоровның комитетның эше турындагы докладын һәм А. И. Лаврентьевның «Славян халыкларының гитлеризмга каршы көрәше турында»гы докладын тыңлады.

Пленум Европаның изелгән славян халыкларына мөрәҗәгать һәм АКШ, Көньяк Америка, Канада, Австралия славяннарына мөрәҗәгать кабул итте. Пленум комитетның якындагы айлар өчен эш планын раслады.

(ТАСС).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫН ЯҢА ҖИҢҮЛӘР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК!



Фармзавод аппаратчицасы Татьяна Лазарева дүрт аппаратта эшләп, планны 200 процентка кадәр үти. К. Тахтеев фотосы.

ҺӘР ГЕКТАРДАН 100 ПОТ ИГЕН УҢЫШЫ АЛУ ӨЧЕН!

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның Көньяк-Көнбатыш, Көньяк, Дон, Төньяк Кавказ, Воронеж, Калинин, Волхов һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре буенча чыгарган 1943 нче ел, 25 нче январь приказын һәм гомумән Кызыл Армиябезнең фронтлардагы уңышлары турында килгән хәбәрләрне Этнә районының Киров исемендәге колхоз члennары чиксез зур рухлану белән каршы алдылар.

Иптәш Сталин приказы басылып чыккан газеталар кулдан-кулга күчеп йөри. Колхозчылар приказның һәрбер сүзен зур диккать белән һәм тирәнтен кызыксыну белән тыңлыйлар һәм өйрәнәләр.

Фронтлардан килгән соңгы хәбәрләрне, Совет Информбюросы белдерүләрен һәм иптәш Сталинның приказын уку өчен чакырылган митинг та шулай ук бик җанлы үтте. Колхоз клубы митингка килгән кешеләр белән шыгырым тулы булды. Сталинград районында чолганып алынган немец-фашист гаскәрләрен кырып бетерү турында Совет Информбюросы белдерүен колхозчылар аеруча зур дәртләнү белән тыңладылар.

Киров исемендәге колхоз членнары иген уңышын күтәрү, терлекчелекне үстерү, героик Кызыл Армиябезгә ярдәмне тагын да көчәйтү буенча киләчәктә тагын да тырышыбрак эшләргә сүз бирделәр. Язгы чәчүгә отлично итеп әзерләнү һәм шулай ук отлично үткәрү, быел бөртекле культураларның һәр гектарыннан кимендә 100 пот иген уңышы алуга ирешү өчен шул ук районның Маркс исемендәге колхозын социалистик ярышка чакырдылар.

А. БАЙБЕКОВ.

АЙЛЫК ПЛАН 143 ПРОЦЕНТКА ҮТӘЛДЕ

ЧИСТАЙ. (Телеграф буенча). Чистай предприятиеләре һәм артельләре, киң куллану товарлары эшләп чыгаруны арттыру буенча казанлылар белән ярышка чыгып, үз өстенә алган йөкләмәләрен арттырып үтиләр. Январь аенда 1 миллион 626 мең сумлык күләмендә киң куллану товарлары эшләп чыгарылды, айлык план 143 процентка үтәлде. Коллективлар февраль аенда тагын да яхшырак эшләү һәм героик Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа уңышлар белән каршылау өчен көрәшәләр.

ВКП(б) ның шәһәр комитеты секретаре СИДАЕВ.
Шәһәр башкарма комитеты председателе ТВЕРЯКОВА.

ТИМЕР ЮЛЧЫЛАР ҖӘВАБЫ

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказын укыгач, Казан тимер юлчылары:

—Һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиягә армый-талмый ярдәм итәрбез, —дип белдерделәр.

Юлбашчының приказына җавап итеп, Әгерҗе депосының алдынгы паровозчылары кривоносча рейслар ясыйлар. 27 нче январьга каршы төндә машинистлардан Волгушев һәм Захаров иптәшләр аеруча яхшы эшләделәр. Алар су алу өчен бары тик бер генә җирдә туктап, Әгерҗедән Вятские Поляны станциясенә почмаклы маршрут ясадылар. Поезд Вятские Поляны станциясенә расписаниедә күрсәтелгәнгә караганда 4 сәгать 20 минутка алдан килде. Участок тизлеге нормасы сәгатенә 32 километр, техник тизлек нормасы сәгатенә 17 километр арттырып үтәлде.

Юдино депосы паровозчылары да иптәш Сталин приказына кривоносча рейслар белән җавап бирәләр. Машинист иптәш Ремизюк мөһим йөк төялгән поездны Шәмәрдәннән Восстание станциясенә 3 сәгать 12 минут элек китерде. Аерым машиналар ягулык күмер һәм утын белән 10 минут эчендә тәэмин ителәләр. Складка берьюлы берничә паровоз килсә дә, аларга ягулык кызу темплар белән төялә. Паровозларга ягулык төяүдә иптәш Шакиров бригадасы алда бара.

ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ СРОГЫННАН ЭЛЕК ҮТӘРГӘ

Завком председателе урынбасары иптәш Горовская булган Н-че заводның барлык цехларында иптәш Сталинның приказына багышланган митинглар булып үтте. Эшчеләр үзләренең чыгышларында һәм митингларда кабул ителгән карарларында киләчәктә тагын да яхшырак эшләргә, фронтка ярдәмне тагын да көчәйтергә сүз бирделәр.

Цехком председателе иптәш Саттаров булган цех коллективы иптәш Сталинның приказына җавап итеп, Кызыл Армия көнен каршылау буенча алган йөкләмәләрен 23 нче февральдә үтәргә карар чыгарды.

Төп цехларның барлык эшчеләре производство планнарын срогыннан элек, арттырып үтәү өчен ярышка чыктылар. Алар, производстводагы алдынгылык өчен көрәшү белән бергә, Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланып үткәрелә торган профсоюз-комсомол чаңгы кроссына да актив катнашырга булдылар.

ЯҢА МАСТЕРСКОЙ

Биектау райпромкомбинаты халык өчен киң куллану товарлары җитештерү эшен җәелдерә. Комбинатның өс киеме тегү, шорный һәм тимерчелек мастерскойлары яхшы гына эшләп киләләр. Шушы көннәрдә Сосновкада сабын кайнату производствосы эшли башлады. 2 мең килограмм сабын эшләп чыгарылды инде. Пермяковскийдагы хезмәт колониясендә балчыктан савыт-саба ясау мастерское эшли башлады. Бу мастерской, кыска гына вакыт эчендә, 2 мең литр сыешлы санда төрле савыт-сабалар эшләп чыгарды.

Д. СКВОРЦОВ.

„БОЛЬШЕВИК“ КОЛХОЗЫНДА

Норлат районының «Большевик» колхозы членнары Кызыл Армиябезнең 25 еллыгын яңа уңышлар белән каршылау өчен армый-талмый эшлиләр.

Колхозда барлык культуралар буенча да чәчүлек орлыклар салынып куелган. Аларның 85 проценты чистартылыган һәм триерланган. Орлык чистартуда яшь кызлардан Җамалова Галия, Вәлиева Мәстүрә һәм Гайниева Хәбирә иптәшләр аеруча тырышып эшлиләр.

Язгы чәчүдә кирәкле булачак барлык авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау тәмамланган. Бу эштә комсомолецлардан иптәш Х. Гыйльфанова аеруча яхшы эшләде.

Кышкы агротехника чараларын үткәрү дә уңышлы бара. 155 гектар мәйданда кар тотылган. Кар тоту өчен куелган щитлар әледән-әле күчерелеп торыла. Кырга 300 йөк тирес чыгарылган. 40 центнер көл җыелган.

Сбруйлар да җитәрлек һәм аларга яхшылап ремонт ясалган.

Р. ХӘСӘНОВА.

СВОДКА.

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 1 нче ФЕВРАЛЕНӘ
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0	37. Чүрибураш	59,6	74. Шөгер	41,5
2. Чокалы	100,0	38. Т. Тамак	59,0	75. Маткауш	41,4
3. Нөркәй	94,3	39. Кукмара	58,9	76. Кызыл юл	40,0
4. Тымытык	91,9	40. Мөслим (Чистай)	58,8	77. Кама тамагы	40,0
5. Алга	90,0	41. Берекәс Май	56,9	78. Иске Писмән	38,3
6. Бөгелмә	89,4	42. Тәтеш	56,2	79. Питрәч	38,3
7. Ишеево	82,9	43. Иске Тимошкино	56,1	80. Солтан	38,2
8. Тирсә	82,5	44. Мәлки	56,0	81. Әхмәмәт	37,3
9. Саба	80,0	45. Балтач	55,8	82. Алексеевский	37,0
10. Алабуга	79,5	46. Бондюг	55,6	83. Буденный	36,8
11. Чүпрәле	79,1	47. Аксубай	55,4	84. Мәйдан	36,2
12. Актаныш	75,0	48. Исәнбай	54,1	85. Кәкре елга	36,1
13. Юртыш	75,0	49. Чыбыклы	53,3	86. Балык бистәсе	36,0
14. Норлат	73,8	50. Әлмәт	52,1	87. Арча	34,9
15. Юдино	73,3	51. Ютазы	52,0	88. Минзәлә	34,8
16. Янил	72,7	52. Баулы	51,9	89. Чишмә	33,3
17. Мөрәле	72,3	53. Акташ	51,7	90. Үзәк	32,4
18. Зөя	71,4	54. Тельман	50,8	91. Макыл	32,0
19. Сарман	69,8	55. Каргалы	50,0	92. Ромадан	31,5
20. Кадряк	67,6	56. Зирекле	50,0	93. Морт	31,4
21. Октябрь	67,2	57. Б. Матак	49,0	94. Казанбаш	30,3
22. Соколка	66,7	58. Рождественский	46,9	95. Мамадыш	29,0
23. Дөбьяз	66,7	59. Столбище	46,3	96. Тат. Ялтан	28,8
24. Азин	66,7	60. Константиновка	46,2	97. Кузнечиха	28,6
25. Тархан	65,6	61. Калинин	46,0	98. Әлшн	28,6
26. Заинский	65,5	62. Иске Чишмә	45,5	99. Трехозерский	26,4
27. Кузайкино	65,5	63. Кичү	45,2	100. Чиябаш	25,4
28. Дәүләки	65,2	64. Салман	44,7	101. Биектау	25,0
29. Половка	63,4	65. Биләр	44,4	102. Әлки	23,2
30. Димитров	62,9	66. Черемуховский	44,4	103. Ключи	20,7
31. Чистай	62,7	67. Әтнә	44,0	104. Кошкино	17,4
32. Куйбышев	62,6	68. Чалпы	43,2	105. Тат. Ходяш	16,7
33. Кызыл йолдыз	61,1	69. Яңа Чишмә	43,1	106. Зур Поляна	15,8
34. Кызыл Чапчак	60,7	70. Теләче	42,9	Барлыгы:	51,3
35. Чаллы	60,0	71. Буа	42,6	1943 нче елның 25 нче январена	46,0
36. Олы Карилә	60,0	72. Карамалы	41,8		
		73. Тәкәнеш	41,5		



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: Уңда—Н-че часть сугышчылары дошманны куып алга таба хәрәкәт итәләр. Сулда—плен төшкән фрицлар тирән тылга озатылалар.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

4 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Украинада безнең гаскәрләр кискен атака нәтиҗәсендә, **Купянск** шәһәрен, шулай ук район үзәкләреннән **Двуречнаяны, Бороваяны** алдылар.

Курскидан көнчыгыштарак безнең гаскәрләр **Щигры** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Тим** шәһәрен, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Черемисиновоны,** район үзәге һәм тимер юл станциясе **Колпныйны** алдылар.

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр район үзәге һәм зур тимер юл узелы **Старо-Минскаяны,** район үзәге һәм тимер юл станциясе **Каневскаяны** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

3 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 4 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм бер батальонга якын дошман пехотасын тараттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Мечетинскаядан төньяк-көнбатыштарак булган бер чиктә дошман куәтле оборона линиясе төзегән булган. Немецлар бик күп санлы ДЗОТ лар, окоплар ясаганнар, тимер чыбык киртәләре корганнар һәм юлларга бик күп миналар куйганнар. Совет частьлары, артиллериянең, танкларның, пехотаның һәм кавалериянең куәтле ударлары белән дошманның обороносын өзделәр һәм дошман урнашкан урынга барып чыктылар. Көчле рәвештә ныгытылган, халык яши торган берничә пункт алынды. Немецлар, үз солдатларының һәм офицерларының йөзләрчә үле гәүдәләрен һәм җимерелгән күп техникаларын калдырып, чигенделәр. Безнең частьлар трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар.

* * *

Красный Лиман районында Н-че гвардия берләшмәсе, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган берничә пунктны алды. Бу пунктларның берсе янында гына да 300 дән артык дошман солдатларының һәм офицерларының үле гәүдәләре табылды. 2 танк, 6 орудие, 19 пулемет, 2 сугыш припаслары склады һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта дошман танкларының һәм пехотасының контратакасы кире кайтарылды. Бер ротага якын гитлерчылар юк ителде һәм немецларның 9 танкысы сафтан чыгарылды.

* * *

Купянск районында дошман елга ярына көчле рәвештә ныгытылган оборона чиге ясаган. Безнең частьлар, шәһәрне көньяктан һәм төньяктан әйләнеп үтеп, шәһәр читләренә бәреп керделәр. Бик каты урам сугышлары нәтиҗәсендә безнең сугышчылар дошманның 1.400 солдатын һәм офицерын кырып ташладылар. 15 танк, 34 орудие, 130 пулемет, 43 миномет, 1.900 винтовка, 12 транспорт, 2 он склады һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Воронеждан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары бер полкка якын немецлар пехетасын юк иттеләр. 16 орудие, 18 пулемет, 17 радиостанция, 6.000 снаряд, 4.000 кул гранатасы һәм башка төрле күп сугыш милекләре кулга төшерелде.. Иптәш Голосов командалыгында һөҗүм итеп алга баручы частька каршы немецлар контратакага 15 танк җибәргәннәр иде. Безнең подразделениеләр дошманның 7 танкысын зарарладылар һәм сафтан чыгардылар һәм тагын да алга барып, халык яши торган бер зур пунктны алдылар. Мылтык-пулемет уты белән немецларның 5 самолеты атып төшерелде.

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсенең Юдино авылында немец венгер кабахәтләр эшләгән көчләүләр һәм мыскыллаулар турындагы акт игълан ителә: «Немецлар һәм аларның венгер иярченнәре безнең авылда бөтен халыкны таладылар һәм бөлдерделәр. Алар крестьяннарның азыкларын һәм кыйммәтле әйберләрен талап алдылар, бөтен халыкны йортларыннан урамнарга куып чыгардылар һәм күп йортларны ат абзарларына әйләндерделәр. Йортларга атларны урнаштырдылар, ә колхозчылар үзләренең семьялары һәм кечкенә балалары белән ачык һавада яки землянкаларда яшәделәр. Фашист басып алучылар, совет кешеләренең дәрәҗәсен төрлечә кимсеттеләр һәм аларны мыскыл иттеләр. Комендант барлык кешеләргә номерлар бирде һәм һәрбер кешене үзенең җиңенә бирелгән номер язылган тасма бәйләп йөрергә мәҗбүр итте. Номерлы тасма такмыйча урамга чыккан өчен оккупантлар ерткыч төстә кыйнадылар һәм штраф түләттеләр. Гитлерчылар бөтен халыкны авылдан 10 километр ераклыкка ныгытмалар төзелешенә кудылар һәм иртә таңнан кич караңгыга кадәр эшләргә мәҗбүр иттеләр. Әйкә соңга калган өчен немецлар камчы белән суктыруны керттеләр. Кызыл Армия ударлары астында чигенгән чакта бандитлар колхезчыларның 70 йортын яндырдылар. Бик күп ирләрне һәм хатын кызларны алар ирексезләп Германиягә фашистлар каторгасына куып алып киттеләр». Актка майор Кичанов, өлкән лейтенант Сироткин, Юдино авылы кешеләреннән Красноштанова, Тимченко һәм башкалар кул куйды.

* * *

Ирекле укчылар отрядлары булып берләшкән Франция патриотлары немец оккупантларга каршы көрәшне көчәйтәләр. Париждагы мәйданнарның берендә бер группа азат укчылар немецлар отрядына берничә граната ыргытканнар. Күп гитлерчылар үлгән һәм яраланган. Кот д. Орда азат укчылар немецларның 5 гарнизонын юк иткәннәр, автоматлар һәм патроннар тутырылган бер склад кулга төшергәннәр. Сен Жермен де Фоссе районында немецларның бер товар поезды юлдан чыгарылган.

ЧЕРЧИЛЛЬНЕҢ ТӨРКИЯДӘГЕ СӨЙЛӘШҮЛӘРЕНӘ КАРАТА

ӘНКАРӘ, 3 февраль. (ТАСС). Черчилль Төркиядә чакта Төркия республикасы президенты Гыйсмәт Иненүгә король Георгның дусларча хатын тапшырган иде. Анатолий телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Төркия президенты Төркиянең Лондондагы илчесе аркылы корольгә җавап җибәргән.

Шул ук агентлыкның хәбәр итүенчә, Төркия республикасы президенты Гыйсмәт Иненү Аданада булган сөйләшүләр вакытында АКШ президенты Рузвельтка телеграмма җибәргән. Бу телеграммасында ул Рузвельтның Черчилль аркылы тапшырылган сәламенә һәм симпатия белдерүенә җавап итеп үзенең рәхмәтен һәм симпатия хисләрен белдерә.

ЛОНДОН, 3 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Кипр атавына килгәч Черчилль Никузиядә (атауның башкаласында) речь белән чыккан һәм болай дигән: «Мин сезгә Төркиядән килдем. Анда мин президент Иненү белән һәм Төркия дәүләте җитәкчеләре белән гадәттән тыш күңелле очрашуда булдым һәм мин сезгә безнең Төркия белән булган мөнәсәбәтләребез гадәттән тыш дусларча характерда икәнлекне шатлык белән белдерәм. Төрекләрнең карашы безнең карашка бик якын һәм без аларның гомуми тынычлыгын ныгытуга бөтен көчебез белән ярдәм итәргә уйлыйбыз.

Без хәзерге вакытта борынгы данын тудырган батыр һәм герой Грециягә тирәнтен теләктәшлек белдерәбез. Греция коточкыч газаплар эчендә, ләкин без инде Грециянең азатлык көне якынаюны күрсәтә торган яктылык нурларын күрәбез.

Без бу сугыш башланганнан бирле бик куркыныч һәм авыр заманнар кичердек. Бу сугышны безгә моннан элек безнең буын тарафыннан кыйналган кешеләр тактылар. Без үзебезнең ахмаклыгыбыз аркасында аларга үзләренең канлы планнарын яңадан әзерләргә мөмкинлек бирдек. Без күп кенә күңелсез һәм кайбер бик күңелсез этаплар аркылы үттек. Ләкин хәзер инде мин сезне ышандыра алам, бәрләшкән милләтләр үзләренең саннары ягыннан гына түгел, гадәттән тыш күп эшләнә торган кораллары ягыннан гына да түгел һәм үзләренең материаль ресурслары ягыннан гына да түгел, бәлки максатлары бердәм булу, иптәшлек һәм ныклы карар биргән булулары ягыннан да кешелек дөньясы тарихында кайчан да булса булып үткән хәрби көчләр берләшмәләренең иң зурысы булып торалар. Берләшкән милләтләр көчлеләр һәм алар тагын да күбрәк көч тупларлар һәм ахырында дөньяны буталчыкка керткән һәм бөлгенлеккә төшергән кешеләрне һичбер сүзсез тез чүгәргә мәҗбүр итәрләр».

Соңыннан Черчилль Кипр халкының дошманны аударып ташларга хәзер торуын әйтеп үткән.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ КЕЛЬНГӘ, БРЮГГЕГӘ ҺӘМ АББИЛЬГӘ ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 3 февраль. (ТАСС). Авиация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, 2 нче февральдә иртә белән Англия бомбардировщиклары, 200 истребитель белән берлектә, Бельгиянең Брюгге шәһәре һәм Франциянең Абвиль шәһәре янындагы сортировка станцияләренә һөҗүм иткәннәр.

ЛОНДОН, 3 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, 3 нче февральгә каршы төндә Англия авиациясе Кельн шәһәрен бик каты бомбага тоткан. 20 минуттан ким вакыт эчендә шәһәргә берничә мең яндыргыч бомбалар һәм бик күп фугаслы бомбалар ташланган. Шулар арасында һәрберсе 1.800 килограмм авырлыктагы 100 бомба ташланган.

Үткән елның 31 нче маена каршы төндә бу шәһәргә 1.000 самолет һөҗүм итеп, 250 промышленность предприятиесен зарарлаганнар иде. Шуннан соң анда немецлар җимерекләрне төзәтү буенча бик тырышып эшләделәр. Ләкин 16 нчы октябрьгә каршы төндә ясалган көчле һөҗүм бу эшләрне өзде. Соңгы һөҗүм бу яктан тагын да зуррак роль уйнаячак.

Соңгы атака вакытында башлыча су асты көймәләре өчен дизель моторлары һәм аккумуляторлар ясый торган зур заводлар, шулай ук Маузерның корал заводы бомбага тотылган.

Оккупацияләнгән илләрдәге хәл

Итальян—немец оккупантлары һәм аларның Павелич яклы ярдәмчеләре—усташилар Югославия халкын ерткыч төстә газаплыйлар. Оккупантлар тоташ авылларны талыйлар һәм яндыралар, ә аларның халыкларын йортларыннан куып чыгаралар. Бу качакларның хәле бик авыр икәнлекне хәтта Недич матбугаты да яшерә алмый. Күп кенә районнарда усташилар, партизаннарның ударлары астында чигенгән чакта, үзләре белән бергә халыкны да куып алып китәләр. «Хрватски народ» газетасының язуына караганда, партизаннар тарафыннан азат ителгән Столац районыннан усташилар чигенгән чакта 2.000 нән артык кешене үзләре белән куып алып киткәннәр. Кышкы салкыннарга да карамастан, алар ачык һавада яшиләр. Землянкаларга урнаша алган кешеләр «бәхетле» саналалар. Йөкле хатыннарны һәм имчәк балалары булган хатыннарны усташилар терлекләр белән бергә урнаштырганнар.

Ләкин Югославия патриотларының азатлык хәрәкәтен берниндә репрессияләр дә бастыра алмый. Партизаннар, дошман гаскәрләренә бик каты каршылык күрсәтәләр. Сански-Мост районында партизаннар 650 дошман солдатын һәм офицерын юк иткәннәр һәм бик күп трофейлар кулга төшергәннәр. Глина-Костайница районында да оккупантлар зур югалтуларга дучар ителәләр. Книн районында партизаннар халык яши торган ике пунктны азат иткәннәр һәм йөздән артык кешене плен алганнар.

Италия һәм Германия авиациясе оккупантлардан азат ителгән пунктларны бомбага тотуын дәвам иттергән. Күп кешеләр, бигрәк тә балалар, хатын-кызлар һәм картлар корбан булган.

Шулай ук Чех-Словакиядә дә азатлык көрәше көчәя. Чех яшьләре урамнардагы автомат телефоннарны бозалар, йортлардан немецча урам исемнәре язылган такталарны алып ташлыйлар һәм башкалар.

Чит ил матбугатының язуына караганда, Чехиядә гитлерчылар терроры һаман көчәя бара. (ТАСС).

Рузвельтның Хэлл белән һәм политик партияләр лидерлары белән киңәшмәсе

ВАШИНГТОН, 3 февраль. (ТАСС). Ак йортның игълан итүенчә, Касабланкада Черчилль белән булган очрашу турында Рузвельт дәүләт секретаре Хэлл белән һәм Конгресстагы демократлар һәм республикачылар партияләре лидерлары белән киңәшмә ясаган.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

◇ 1939 нчы елның сентябреннән 1942 нче елның декабрена кадәр Канада 355 миллион доллрлык суммага оборона характерындагы корылмалар төзелешенә договорлар төзегән. Төп игътибар хәрби һава көчләре өчен һәртөрле корылмалар төзүгә бирелә. Мәсәлән, хәзер анда 560 ангар, 200 аэропорт һәм һәртөрле 1.700 бина салынып ята.

◇ 29 нчы декабрьда Югославиядә Үзәк Босния районында җир тетрәү башланган иде. Озакка сузылуы ягыннан бу җир тетрәүне Европада рекорд тетрәү дип әйтергә мөмкин. Беренче атнада ударлар чирек сәгать саен диярлек булып торган. Хәзер көн саен 5—6 удар сизелә.

БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) ның Өлкә һәм шәһәр комитетларының партия мәгарифе йортында (Бауман урамы, 62 нче йорт, телефон АТС 73—56), 6 нчы февральдә, кич 7 сәгатьтә лекция була. Тема: «Бөек Ватан сугышының агымдагы моменты». Лектор Звонкович. Һәркем керә ала.

* * *

Бүген кич 7 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта партия, совет, хуҗалык оешмалары җитәкчеләренең һәм медицина работниклары активының шәһәр күләмендәге җыелышы була. Көн тәртибе: Шәһәрнең санитария-эпидемия хәле турында. Докладчы—РСФСР Сәламәтлек Саклау Халык Комиссары урынбасары иптәш **Виноградов.**

Җаваплы редактор урынбасары **ГАЛИМ РЯБКОВ.**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—11. типография 36—60.

ПФ481 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 208